СОВЕТ ЛЕБЕДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с. Лебедино

19.08.2019 № 130

**“ТатарстанРеспубликасы Алексеевскогомуниципаль районы Лебедино авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында”гы ТатарстанРеспубликасы Алексеевскогомуниципаль районы Лебедино авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 нче маддәләрен, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 6 октябрь, 2003 ел, 131-ФЗ законын, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Лебедино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставын кулланма итеп алып, 2019 елның 10 августында халык алдында тыңлаулар йомгакларын (тәкъдимнәрне) исәпкә алып,

**Лебединоавыл җирлеге Советы карар бирде:**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы ЛебединоавылҗирлегеСоветының 25.04.2013 ел, 89 нчы карарыбеләнрасланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебединоавылҗирлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбән дәгеүзгәрешләрне кертергә, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзү зонасы картасында үзгәртергә:

Лебедино авылының төньяк-көнбатыш өлешендә, атап әйткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Лебедино авыл җирлеге, Лебедино авылы, Заречная урамы, 41 нче йорт, Р1 территориаль зонасының бер өлеше (гомуми файдаланудагы үзләре үсеп чыккан утыртмалар һәм ачык яр буе территорияләре) Ж1 территориаль зонасына (индивидуаль торак төзелеше зонасы) үзгәртелде. Территориаль зонаның үзгәртелгән өлешенең гомуми мәйданы 0,4 га тәшкил итә.

Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:05:100101:850.

Березовая Грива авылының төньяк өлешендә СХ1 территориаль зонасының (авыл хуҗалыгы җирләре зонасы) бер өлеше, СХ2 территориаль зонасының (авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм корылмалары урнашкан зона) бер өлеше, ВФ2 зонасы (су объектлары зонасы) тулысынча һәм Р1 зонасы (гомуми файдаланудагы үзләре үсеп чыккан үсентеләр һәм яр буе территорияләре) тулысынча Ж1 территориаль зонасына (шәхси торак төзү зонасы) үзгәртелде.

Территориаль зоналарның үзгәртелгән өлешләренең гомуми мәйданы 22,8 га тәшкил итә.Әлеге территориаль зона урнашкан кадастр кварталы: 16:05:100101 (кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка хәбәр итәргә.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Ю.И. Тюкарев**

Лебедино авыл жирлегеСоветының 19 август, 2019 ел, 130 нчы карарына кушымта

**Карта градостроительного зонирования территории Лебединского сельского поселения Алексеевского муниципального района**

